# ӘНИЕМНЕҢ ЖЫЛЫ КОЧАГЫ

*ӘНВӘР БАКИРОВ музыкасы*
*МӨНИР МАЗУНОВ сүзләре*

Сөекле әниемнең
Борчыгандыр жанын
Күңелемнең көйсез һәр чагы.
Еласам, юаткан,
Иркәләп уйнаткан
Әниемнең жылы кочагы.

Уйнаудан туйганда,
Талчыгып калганда,
Ял сорагач керфек очларым,
Жыр көйләп, тирбәтеп,
Йоклаткан изрәтеп
Әниемнең жылы кочагы.

Давыллы көннәрдә,
Ышыклап жилләрдән,
Күкрәгенә кыскан кем тагы?
Кадерләп үстергән,
Яшәргә көч биргән
Әниемнең жылы кочагы.